Кукмара муниципаль районы
Янил авыл башкарма комитеты

Карар

22 март 2021 ел №4

Янил авыл башкарма комитетының 2020 елның 01 октябрендәге 11 номерлы карары белән расланган агач һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын кисүгә яисә утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Янил авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендә булган җирләргә кермәгән җирләрдә яшел утыртмаларны кисү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 15 февралендәге 3 номерлы Янил авыл җирлеге Советы карары нигезендә карар бирәм:

1. 2020 елның 01 октябрендәге 11 номерлы Янил авыл башкарма комитеты карары белән расланган агач һәм куаклар кисүгә, ябалдашларын кисүгә һәм утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.6 пунктына түбәндәге эчтәлекле 2 нче пунктчаны өстәргә:

«2) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына – Россия Федераль салым хезмәте бюджетына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булу (булмау) турында, авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш, белешмәләр.»;

1.2. 2.8 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4 нче пунктчаны өстәргә:

«4) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булу.»;

1.3. 3.4.1 пунктының беренче абзацында «һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булу (булмау) турында белешмәләр» сүзләрен өстәргә.

2. «Янил авыл башкарма комитетының 2020 елның 01 октябрендәге 11 номерлы карары белән расланган агач һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын кисүгә яисә утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 15 февралендәге 3 номерлы Янил авыл башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

Җитәкче И. Х. Корбанов